**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Чубар-Абдул авыл җирлеге Советы карары**

ав. Чубар-Абдул №118 "15" октябрь 2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Советының 2014 елның 21 ноябрендагы № 125 "Җир салымы турында" карарына үзгәреш кертү турында. (2015 елның 15 августындагы №125, 2017 елның 3 августындагы №63 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 52 статьясына һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 03 августындагы 334-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Чубар-Абдул авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Советының 2014 елның 21 ноябрендагы № 125 "Җир салымы турында" карарына үзгәреш кертү турында. (2015 елның 15 августындагы №125, 2017 елның 3 августындагы №63 карарлар редакциясендә) үзгәрешләр кертергә, түбәндәге эчтәлекле 6 пунктчаның 4 пунктын тулыландырып:

“6) балачактан инвалидлар, инвалид балалар. "

2. Әлеге карар рәсми матбугат басмасында басылып чыккан көннән алып бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта - "Маяк" газетасында үз көченә керә һәм физик затларның җир салымын 2015 елның 1 гыйнварыннан исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны «Маяк» район газетасында бастырып чыгарырга, веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда урнаштырырга: http://pravo. tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының веб-адрес буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http//aznakayevo. tatastan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны бюджет, финанс, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Н. Ә. Фәтхетдинов